Үзәкләштерелгән дини оешма

РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ

بسم الله الرحمن الرحيم

# ИЗГЕ РАМАЗАН

АЕ ҖИТҮЕ УҢАЕННАН

РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ РӘИСЕ

## БАШ МӨФТИ ШӘЕХ
## РАВИЛ ГАЙНЕТДИН

# МӨРӘҖӘГАТЕ

**Мәскәү**
1 Рамазан, 1447 ел
19 февраль, 2026 ел

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

*Бисмилләһиррахмәниррахим!*

الحمد لله رب العالمين

والصلاة والسلام على رسول الله

وعلى آله وصحبه اجمعين

وبعد

Җирдәге вә күк йөзендәге бар мәхлүкат тарафыннан макталучы, һәрнәрсәне Үз мәрхәмәте белән колачлаган галәмнәрнең Хуҗасы Аллаһу Сөбханәһу вә Тәгаләгә мактау булсын!

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлламгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм Кыямәт көненә кадәр алар юлында булучыларга Раббыбызның рәхмәте яусын!

السَّلَامُ عَلَيْكُمْ وَرَحْمَةُ ٱللَّهِ وَبَرَكَاتُهُ

Сезгә Аллаһы Тәгаләдән иминлек, Аның рәхмәтен һәм бәрәкәтен сорыйм, кадерле дин кардәшләрем!

Россия Федерациясе мөселманнары диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән сезне һәм якыннарыгызны ихластан изге Рамазан ае башлануы белән котлыйм!

Без елның иң мөбарәк вакытын каршы алабыз, ул — кардәшлек, шәфкатьлелек, риясызлык һәм әхлакый камиллек вакыты. Рамазанга багышланган Коръән аятьләрендә Аллаһы Тәгалә безгә болай ди:

يُرِيدُ اللّهُ بِكُمُ الْيُسْرَ وَلاَ يُرِيدُ بِكُمُ الْعُسْرَ وَلِتُكْمِلُواْ الْعِدَّةَ وَلِتُكَبِّرُواْ اللّهَ عَلَى مَا هَدَاكُمْ وَلَعَلَّكُمْ تَشْكُرُونَ

**«Аллаһ сезгә җиңеллек тели, авырлык теләми һәм Рамазан уразасын тутырып тотуыгызны һәм Аллаһ туры юлга күндергәне өчен Аны олылавыгызны тели, шаять, Аллаһка шөкер итәрсез»**
(*«әл-Бәкара» сүрәсе, 185 нче аять*).

Кайберәүләр уразаны авыр гыйбадәт дип уйлый. Ләкин Аллаһы Раббыбыз ураза тотуны Үз Рәхмәте белән җиңеләйтәчәгенә басым ясый. Танылган дин белгече Абдулла Йосыф Али бу хакта болай язган: «Куелган таләпләр ике әйбер белән бәйләнә:

а) бирелгән шартлар вә вәгъдә; б) ураза тотуның рухи әһәмияте, аннан башка ураза төшсез кабыкка тиң. Без моны аңлый алсак, Рамазан аена авыр йөк һәм бурыч итеп карамыйча, бу вакыт өчен дә, бирелгән күрсәтмәләр өчен дә рәхмәтле генә булыр идек».

Аллаһының рәхим-шәфкате Аның икенче бер бүләге — дога, ягъни Раббыбызга ялвару рәвешендә дә дәвам итә, кызганыч, без бу хакта гамсезсезлегебез аркасында онытып кына җибәрәбез. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәллам болай дигән:

«*Ураза тотучының догасы ураза көне дәвамында кабул ителә*»
(әл-Баззар хәдисләр җыентыгы).

Шулай итеп, әлеге изге ай адәм балаларында киң күңеллелек, игелеклелек, мәрхәмәтлелек тәрбияләргә тиеш. Шуңа бәйле рәвештә, Рамазанны Илаһи мәрхәмәт чоры буларак кабул итү белән беррәттән, кешеләргә дә мәрхәмәт һәм кешелеклелек күрсәтү вакыты буларак аңларга чакырам.

Шәхси мәшәкатьләрегезне читкә куеп, әйләнә-тирәгә күз салыгыз. Анда, кызганыч, миллионлаган кеше бик авыр сынауларга очрап, газап чигә, мохтаҗлык кичерә. Бу мөбарәк көннәрдә без «үзебезнекеләр белән читләр»гә бүлмичә, тирә-юньдәге һәркемгә ярдәм итәргә, шатландырырга, юмарт һәм киң күңелле булырга тиеш. Бу быел, Россия халыклары бердәмлеге елында аеруча мөһим.

Бу айны ихлас догалар, Аллаһны зикерләү, Коръән уку һәм башка игелекле гамәлләр белән тулыландырырга чакырам. Үз күңелебезгә ачкыч табып, аның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерә алсак иде. Әлегә Аллаһының юлыннан читтәрәк булганнарга Рамазан ае иманны үзәккә куярга һәм уразада салынган орлыклардан ярдәмчеллек, шәфкатьлелек, ихласлык, юмартлык, илтифатлылык кебек сыйфатларны үстерү өчен менә дигән мөмкинлек.

Мәрхәмәтле Аллаһы Раббыбыз бу Рамазан аенда барыбызның да гөнаһ-хаталарын гафу итсен! Коръәни Кәримдә болай әйтелгән:

إِنَّ الْحَسَنَاتِ يُذْهِبْنَ السَّيِّئَاتِ

«**Һичшиксез, яхшы гамәлләр начар эшләрне йола**»
*(«Һуд» сүрәсе, 114 нче аять).*

Һичшиксез, ураза тотуны, башка йолаларны үтәүне һәм иң мөһиме: бер-беребезгә карата гадел мөнәсәбәттә булуны үз эченә алган ихлас гыйбадәт тәнебезгә шифа, күңелебезгә тынычлык бирә һәм Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешүгә китерә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлламнең түбәндәге сүзләре билгеле:

إن شهر رمضان شهر أمتي، يمرض مريضهم فيعودونه

*«Хакыйкатьтә, Рамазан — өммәтемнең ае,*
*һәм берәрсе авырса, мөэминнәр аның*
*янына барып хәлен белешә...»*
(ибне Хиббан җыентыгы);

لَنْ تُؤْمِنُوا حتى تراحمُوا. . . إنَّهُ ليس
بِرَحْمَةِ أَحَدِكُمْ صاحبَهُ، ولَكِنَّها رَحْمَةُ العَامَّةِ

*«Бер-берегезгә карата мәрхәмәтле булмый торып, сез иман китермәячәк... Һәм бу берегезнең дустына күрсәткән мәрхәмәте түгел... Бу, гомумән, бар кешеләргә күрсәтелергә тиешле мәрхәмәт»*
(әт-Тәбәрани җыентыгы).

Пәйгамбәребезнең сөннәтеннән килүче бу гамәлләрне тормышка ашырыр өчен Аллаһы Тәгалә барыбызга да көч һәм күңел күтәренкелеге бирсен! Бу бөек айда игелекле гамәлләрне күбрәк кылыйк, йөрәк түребездәге иманыбыз ныгысын!

Җир шарындагы һәр йортта тынычлык, иминлек һәм үзара аңлашу хөкем сөрсен! Аллаһы Тәгаләнең «әр-Рахман» һәм «әр-Рахим» кебек бөек исемнәре гел телебездә булсын! Рәхимле Раббыбыз барыбызны да гафу кылсын! Әәмиин, йә Рабби!

**Рамазан мөбарәк булсын, кадерле дин кардәшләрем!**

والسلام عليكم ورحمة الله وبركاته

***Сезнең өчен кардәшлек догасында калучы***
***баш мөфти шәех Равил Гайнетдин***
***Россия Федерациясе мөселманнары диния нәзарәте рәисе***